КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 апрель г.Казань № 417

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 ел, 10 июнь, 471 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 ел, 10 июнь, 471 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 апрель, 242 нче; 2019 ел, 26 апрель, 345 нче; 2020 ел, 23 июнь, 522 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8.9 пунктта «медицина ярдәме күрсәтү күләмнәрен, срокларын, сыйфатын һәм шартларын контрольдә тотуны оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.18 пунктта «, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү» сүзләрен «һәм өстәмә һөнәри белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

9.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.13. Мәҗбүри медицина иминиятенә иминият кертемнәрен исәпләү дөреслеген, тулысынча һәм үз вакытында түләүне (күчерүне) контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы органнан мәҗбүри медицина иминиятен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны ала.»;

9.26 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин